УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ
ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ
СОСТОЯНИЕМ
САМОХОДНЫХ МАШИН И
ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ
БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ
ТЕХНИК ТОРЫШЫНА
КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.10.2020 Казан шәһәре № 01-05/166-пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2018 елның 18 маендагы 01-05/140-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2018 елның 18 маендагы 01-05/140-пр номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2019 елның 5 июнендәге 01-05/121-пр номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәреш кертеп, 5.3 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Беркетмә рәсмиләштерү вакыты Иҗтимагый совет утырышы уздырылганнан соң җиде көннән дә артмый».

Җитәкче Р.Р. Зыятдинов